ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ **КАРАР**

5 май, 2023 ел № 23/5

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, ««Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 6 февралендәге 12-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2011 елның 26 маендагы 12/7 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты статусы турында Нигезләмәнең (Шәһәр Советының 2016 елның 7 апрелендәге 7/20, 2018 елның 21 февралендәге 23/12, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/22, 2019 елның 6 декабрендәге 34/15, 2020 елның 17 июнендәге 40/4, 2020 елның 11 августындагы 41/14, 2021 елның 3 ноябрендәге 9/6 номерлы Карарлары редакциясендә) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачуны һәм ия булуны, акчалар һәм кыймәтле әйберләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны, бурычларны үтәмәүне әгәр әлеге Федераль законда башкасы каралмаган булса;».

2) түбәндәге эчтәлектәге 13 пункт өстәргә:

«13) депутат алты ай рәттән муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органының барлык утырышларында җитди сәбәпләрсез катнашмаган очракта.».

2. Әлеге Карар, гамәлдәге законнар белән үз көченә керүнең башка сроклары каралган нигезләмәләрдән тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев